| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.09. 2019 ел** | **КАРАР**<br>**№ 9** |

**Кошман авылы**

**Кошман авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР** кабул итте:

1. Кошман авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

“Сез, 2020 елда Кошман авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән һәм үзара салымнан кергән керемнең түбәндәге юнәлешләрдә тотылуы белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-җәяүлеләр өчен күперләр ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-кое,чишмәләр ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

-суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

-юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

-авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

-зиратларның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау, моның өчен материаллар һәм җиһазлар сатып алу”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати– телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://kushman-kaybici.tatarstan.ru.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советына юлларга.

4. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кошман авыл җирлеге башлыгы** **Л.Р.Сафина**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Кушманского сельского поселения ИНН 1621003133